Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXVIII - 1**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 8 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының 2017 елдагы социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2018 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Р.Таҗетдиновның 2017 елдагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2018 елга бурычлар турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы җирле үзидарә органнары алдында ел дәвамында хәл итүне таләп иткән берничә төп мәсьәлә торганын билгеләп үтә: бу – икътисадның реаль секторы үсешендә уңай динамиканы саклап калу булды, ә бюджет тулылыгы, социаль, демографик һәм икътисади үсеш перспективалары аңа бәйле.

2017 елда районның берләштерелгән бюджетына 729,8 млн. сум кергән, шул исәптән үз керемнәре буенча план үтәлеше 111,5% тәшкил итә (аныкланган план буенча 191,1 млн. сум урынына берләштерелгән бюджетка 213,0 млн. сум кергән), үз чараларыбыз белән тәэмин ителеш 29,2 % тәшкил итте. Бюджетның керемнәр буенча үтәлеше бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакын тулы күләмдә түләргә, бюджет өлкәсе учреждениеләренең коммуналь түләүләрен һәм район бюджетында каралган башка чыгымнарны башкарырга мөмкинлек бирде. Берләштерелгән бюджетның чыгым өлешен үтәү 725,6 млн. сум тәшкил итте.

2017 елда тулай территориаль продукт 6,1 млрд. сум тәшкил итте, шул исәптән җан башына 236,7 мең сум (2015 ел дәрәҗәсенә карата 114 %). Район буенча хезмәт хакы 6%ка артты һәм эре һәм урта предприятиеләр буенча бер кешегә 22917 сум тәшкил итте.

2017 елда авыл хуҗалыгында тулай продукция җитештерү район буенча 2 637,0 млн. сум тәшкил итте, бу 2016 ел белән чагыштырганда 607,6 млн. сумга күбрәк. Районның авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә һәм крестьян-фермер хуҗалыкларында 12757 баш мөгезле эре терлек бар, шул исәптән 4,2 мең баштан артык сыер, 570 баштан артык ат, бер елда сарыклар саны шактый арткан һәм 1117 баш тәшкил иткән (2016 ел - 890 баш). Шул ук вакытта африка чумасы буенча чикләү чаралары аркасында 1282 дуңгызлар саны башка кимегән һәм 6372 баш тәшкил иткән.

Төзелеш программаларын тормышка ашыру буенча зур эшләр башкарылды. 13,0 мең кв.м. торак файдалануга тапшырылды. 111 шәхси торак йорт төзелде һәм файдалануга тапшырылды. Спорт объектларының, сәламәтлек

саклау, мәгариф, мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту буенча системалы эш алып барылды.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү мәсьәләләрендә күп кенә проблемаларга да игътибар бирә. Аерым алганда, үлүчеләр санының югары булуы борчу тудыра, яшьләр белән эшләүне көчәйтү таләп ителә, белем бирү сыйфатын яхшырту буенча эшне дәвам итәргә кирәк. Салым базасын арттыру һәм район бюджетына кертемнәрнең өстәмә чыганакларын эзләү системалы эш таләп итә. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә һәм авылда хуҗалык итүнең кече формаларын үстерүгә аерым игътибар бирергә кирәк.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Р.Таҗетдиновның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының 2017 елдагы социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм 2018 елга бурычлар турында хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетына:

район территориясендә федераль, республика һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен үтәүне тәэмин итәргә;

белем бирү оешмаларының эш сыйфатын педагогларның һөнәри үсеше, укучылар белән һөнәри юнәлеш эшен оештыру, түбән өлгерешле балалар белән эшләүне оештыру юлы белән арттырырга;

Лев Толстой елы кысаларында билгеләнгән чараларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына халыкны крестьян-фермер хуҗалыкларына һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итү, экологик хәлне яхшырту чараларын үткәрү программаларында катнашуга җәлеп итү буенча максатчан эш алып баруны тәкъдим итәргә.

4. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенә авыл җирлекләре башлыклары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, җәмәгать оешмалары белән берлектә законлылыкны һәм хокук тәртибен алга таба ныгытуны тәэмин итәргә, ирекле халык дружиналарын үстерүгә, юл-транспорт һәлакәтләрен һәм хокук бозуларны, экстремизм һәм террорчылык күренешләрен профилактикалауга аерым игътибар бирергә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Аппаратына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының әлеге утырышы, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләрендә халык белән очрашулар барышында әйтелгән искәртүләр һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны үтәү чараларын күрергә.

6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының даими комиссияләренә үз компетенциясе кысаларында кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп торырга.

7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының 2017 елдагы социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2018 елга бурычлары турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручының хисабын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов